КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 сентябрь г.Казань № 836

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар мәйданчыклары системасын төзү һәм аның эшләве турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1260 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар мәйданчыклары системасын төзү һәм аның эшләве турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1260 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировкалар мәйданчыклары исемлегенең 1 нче пунктындагы 3 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Норматив хокукый актларга коррупциягә каршы экспертиза.

Норматив хокукый актлар проектларын эшләү»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең стажировкаларын оештыру һәм үткәрү регламентының 1 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гомуми нигезләмәләр

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның

27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировка мәйданчыклары системасы турында» 2018 елның 18 августындагы ПУ-574 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең стажировкаларын оештыруның һәм уздыруның әлеге регламенты (алга таба – Регламент) нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте дәүләт органнарында (алга таба – хакимиятнең башкарма органнары) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарында (алга таба – җирле үзидарә органнары) стажировка мәйданчыкларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр (алга таба – хезмәткәрләр) стажировкаларын оештыру һәм үткәрү тәртибе билгеләнә.

Стажировка мәйданчыгында хезмәткәрләр тарафыннан өстәмә һөнәри белем алу стажировка формасында гамәлгә ашырыла торган квалификация күтәрү программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

Стажировканың максаты – хезмәткәрнең теоретик һәм практик белемнәрен ныгыту һәм хезмәткәрне стажировкага җибәргән башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы функционалы нигезендә аңа йөкләнгән эшне мөстәкыйль рәвештә башкару күнекмәләрен һәм осталыкларын үстерү.

Стажировка мәйданчыклары системасында «җитәкчеләр» категориясе вазыйфаларын бер елдан ким биләгән һәм күрсәтелгән вазыйфаларга беренче тапкыр билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, шулай ук муниципаль хезмәтнең иң югары һәм төп вазыйфаларын бер елдан кимрәк биләгән һәм күрсәтелгән вазыйфаларга беренче тапкыр билгеләнгән Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең, тиешле җирле үзидарә органнары белән килештереп, стажировкасы оештырыла.

Дәүләт органы, җирле үзидарә органы соравы буенча стажировка мәйдан-чыклары системасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең стажировкасы оештырыла.

Стажировка хезмәткәрнең даими эш урыныннан читтә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү дәүләт программасын гамәлгә ашыруга каралган тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән уздырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин